**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы территориясендә аучылык биләмәләрен урнаштыру, файдалану һәм саклау схемасына үзгәреш кертү турында**

Аучылык биләмәләрен рациональ файдалануны оештыру буенча чараларны камилләштерү максатларында **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы территориясендә аучылык биләмәләрен урнаштыру, файдалану һәм саклау схемасын раслау турында» 2015 елның 3 октябрендәге ПУ-968 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2018 елның 19 маендагы ПУ-381 номерлы һәм 2021 елның 21 декабрендәге ПУ-979 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы территориясендә аучылык биләмәләрен урнаштыру, файдалану һәм саклау схемасына, 6 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 6.5 пунктчасы өстәп, үзгәреш кертергә:

**«6.5. Ау токымы этләрен ауга өйрәтү һәм әзерләү зоналары**

Ау токымы этләрен ауга өйрәтү һәм әзерләү, аларның эш күнекмәләрен үстерү максатларында аучылык биләмәләрендә ау токымы этләрен ауга өйрәтү һәм әзерләү зоналары булдырыла.

Беркетелгән аучылык биләмәләрендә ау токымы этләрен ауга өйрәтү һәм әзерләү путевка нигезендә башкарыла. Ау токымы этләрен ауга өйрәтү һәм әзерләү вакытында аучылык ресурслары аулау күздә тотылмый, ул ау чорында, шулай ук ау чоры булмаган вакытта да башкарылырга мөмкин.

Түбәндәге аучылык хуҗалыкларында ау токымы этләрен ауга өйрәтү һәм әзерләү зоналары билгеләнгән:

Азнакай муниципаль районында – «Азнакай» аучылык хуҗалыгы;
Аксубай муниципаль районында – «Аксубай» аучылык хуҗалыгы;
Әлмәт муниципаль районында:
«Бутино-Чишмә» аучылык хуҗалыгы;
«Кама-Исмәгыйль» аучылык хуҗалыгы;
Арча муниципаль районында – «Үрнәк» аучылык хуҗалыгы;
Бөгелмә муниципаль районында – «Бөгелмә» аучылык хуҗалыгы;
Алабуга муниципаль районында:
«Алабуга» аучылык хуҗалыгы;
«Свиногорье» аучылык хуҗалыгы;

Зеленодольск муниципаль районында:

«Олы Карагуҗа» аучылык хуҗалыгы;

«Зеленодольск» аучылык хуҗалыгы;

Лаеш муниципаль районында – «Кама киңлекләре» аучылык хуҗалыгы;

Лаеш һәм Балык Бистәсе муниципаль районнарында – «Янтык» аучылык хуҗалыгы;

Лениногорск муниципаль районында – «Селәүсен» аучылык хуҗалыгы;

Мамадыш муниципаль районында – «Нократ яры» аучылык хуҗалыгы;

Минзәлә муниципаль районында – «Яңа Минзәлә» аучылык хуҗалыгы;

Мөслим муниципаль районында – «Мөслим» аучылык хуҗалыгы;

Түбән Кама муниципаль районында:

«Сухарево» аучылык хуҗалыгы;

«Чишмә» аучылык хуҗалыгы;

Питрәч муниципаль районында – «Питрәч» аучылык хуҗалыгы;

Спас муниципаль районында – «Куйбышев» аучылык хуҗалыгы;

Тәтеш муниципаль районында – «Тәтеш» аучылык хуҗалыгы;

Чирмешән муниципаль районында – «Чирмешән» аучылык хуҗалыгы.».

2. Әлеге Указ рәсми басылып чыккан көненнән 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2022 ел, 26 июль
№ ПУ-496